| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кадыбашского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадыбаш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 31.01.2019 | Кадыбаш авылы | № 48-3 |

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Кадыбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 15 сентябрендәге 1094 санлы, "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 15 декабрендәге 1572 санлы Карарлары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Кадыбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 сентябрендәге 43-1 санлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктта:

а) 8 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

"Каты коммуналь калдыкларны чыгару – каты коммуналь калдыкларны урыннардан (мәйданчыклардан) җыеп алу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, каты коммуналь калдыкларны күмү өчен файдаланыла торган объектларга кадәр ташу»;

"Контейнер мәйданчыгы" – әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләре һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән һәм контейнерлар, бункерлар урнаштыру өчен билгеләнгән каты коммуналь калдыкларны җыю урыны (мәйданчыгы);

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Каты коммуналь калдыкларны төяү – каты коммуналь калдыклар җыелу урыннарыннан (мәйданчыклардан) күчерү, каты коммуналь калдыклар яки каты коммуналь калдыклар төяү башкарыла торган башка урыннар, аларны транспортировкалау, шулай ук каты коммуналь калдыклар төяү урыннарын җыештыру;

Каты коммуналь калдыкларны төяү урыннарын җыештыру – каты коммуналь калдыкларны төяү һәм аларны чүп ташый торган машинага күчерү буенча эшләр".

2. Әлеге карарны http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе И.Г. Рамазанов